РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Исполнительный комитет Варваринского сельского поселения *Камско-Устьинского* муниципального района**

ул. Ленина, 28, с. Варварино, 422825
тел. (8277)32-6-09, факс: (8277) 32-6-09

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы Варварино авыл җирлеге Башкарма комитеты**

Ленин урамы, 28,Варварино авылы, 422825,
тел. (8277)23-6-09, факс: (8277) 32-6-09

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның 31 гыйнвары № 2

2024 елга «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Варварино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 3 пункты һәм 12 статьясындагы 3 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2024 елда пособиеләр, компенсацияләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» 2024 елның 23 гыйнварындагы 46 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Варварино авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның 1 февраленнән «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Варварино авыл җирлеге " муниципаль берәмлегендә 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 8370сум 20тиен күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2023 елга җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган

хезмәтләр хакын раслау турында» 2023 елның 31 гыйнварындагы 2 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карар 2024 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының Варварино авыл
җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Р.Т.Нотфуллин

1 нче кушымта Кама Тамагы
муниципаль районы Варварино
башкарма комитетының 2024 елның
31 гыйнварындагы 4 номерлы
карарына 1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Варварино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2024 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән исемлегендәге хезмәтләрнең бәяләре

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 5015,64 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка (крематорийга) илтү | 713,73 |
| 4. Җирләү (мәетне яндыру һәм көле салынган урнаны тапшыру) | 2640,83 |
| Барлыгы | 8370, 20 |

Кама Тамагы муниципаль районы
Варварино Башкарма комитетының
2024 елның 31 гыйнварындагы 4
номерлы карарына 2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Варварино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2024 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән исемлегендәге хезмәтләрнең бәяләре

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 257,40 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 4758,24 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка (крематорийга) илтү | 713,73 |
| 5. Җирләү (мәетне яндыру һәм көле салынган урнаны тапшыру) | 2640,83 |
| Барлыгы | 8370,20 |